МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.11.2022 Казан ш № 989

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 971 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 971 номерлы боерыгы ( Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 27 июнендәге 627 номерлы боерыгы керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне (алга таба – Үзгәрешләр) расларга.

2. Әлеге боерык, Үзгәрешләрнең 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керәчәк беренче абзацыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.11.2022 ел, № 989 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 971 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

Дүртенче-җиденче, тугызынчы, унсигезенче һәм унтугызынчы абзацларда «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга;

4.2 пунктта «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар (физик затлар) регистрын алып бару тәртибе турында» 2010 елның 8 ноябрендәге 972 номерлы боерыгы белән расланган Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар (физик затлар һәм эш бирүчеләр) регистрын алып бару тәртибенең» сүзләрен «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2021 елның 6 декабрендәге 871н номерлы боерыгы белән расланган Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затларның регистрларын алып бару тәртибен, шул исәптән аларга белешмәләр кертү тәртибен, чорларын һәм белешмәләр рәвешен, шулай ук халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрларында булган мәгълүмат төрләре исемлегенең» сүзләренә алмаштырырга;

4.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Белешмә телефоннар, дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) урнаштырыла.»;

кушымта (белешмәлек) үз көчен югалткан дип танырга.